
Нигъмәтуллина, З.   Матурлык нигезе - тырышлык / З. Нигъмәтуллина // Мәдәни җомга. – 2022. – №47 (2 декабрь). – Б. 24.



# Матурлык нигезе – тырышлык





*Чаллы рәссамы, декоратив-гамәли сәнгать остасы Люция Амосова 1982 елда Ульян өлкәсендәге Иске Атлаш авылында туган. Аңа 5 яшь булганда, гаиләләре Яр Чаллыга күченгән. «Әнием Роза биредәге 66 нчы ятимнәр мәктәп-интернатында тәрбияче-методист булып эшләде, хәзер ул лаеклы ялда. Әтием Камил Хәсәнов та шушы мәктәп-интернатта музыка укытучысы булып хезмәт итте, фортепиано, баян, акккордеон классын алып барды. Әтием композитор буларак та билгеле. 1999 елда «Назлы моң» җырлар җыентыгын да нәшер итте. Кызганыч, 2000 елда һәлак булды.*

1999 елда Казан дәүләт университетына укырга кердем, аны 2004 елда экономист-менеджер белгечлеген алып тәмамладым. 2009-2014 елларда Яр Чаллы Социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институтының сәнгать-графика факультетында белем алдым. Сынлы сәнгать укытучысы белгечлегем булгач, 2014 елда 9 нчы Балалар Дингез үзәгендә өстәмә белем педагогы булып эшли башладым, укучыларны рәсем ясарга, декоратив-гамәли сәнгатькә өйрәттем, «PROделки» иҗат берләшмәсен җитәкләдем. Андагы балалар төрле күргәзмә, бәйгеләрдә бик актив катнаштылар. 2015-2016 елда «Логопедия» программасы буенча һөнәри белемемне арттырдым һәм укыту программабызга «логопедияле рәсем ясау» дәресләрен дә керттем», – диде талант иясе.

Л.Амосованың «Илһам» дип аталган беренче шәхси күргәзмәсе 2015 елда Яр Чаллы үзәк китапханәсе галереясында ачылган. 2017 елдан башлап Люция балалар бүлмәләре интерьерлары өчен анималистика темасындагы акварель рәсемнәр серияләрен иҗат иткән, батик, күн мозаика элементлары кергән кием-салым дизайны белән шөгыльләнгән, Вологда челтәр бәйләме ысулында төрле әйберләр үргән... Хәзер ул челтәрле сетка нигезне сокландыргыч рәсемнәр белән тулыландыра. Бер әсәре ким дигәндә 2 ай үрелә!

Рәссам 2020-2021 елларда үзәк китапханәдәге сәнгать бүлегендә эшләп, төрле мәдәни чаралар оештыруда, күргәзмәләр ачуда катнаша, балалар белән шәхси дәресләр алып бара. «Соңгы вакытларда шәрык мәдәнияте белән кызыксынам», – дип ачыклады Люция ханым.


2020 елдан алып ул Татарстан Рәссамнар берлегенең Яшь рәссамнар иҗат берләшмәсе сафында. Төрле арт-проектларда, күмәк күргәзмәләрдә актив катнаша, үз көчен конкурсларда да сыный. Әйтик, «Ел рәссамы» конкурсларында көч сынаша, «Ел педагогы – 2016» конкурсында да үз осталыгын раслаган. Яңа елда аны Төзүчеләр мәдәният йортында шәхси күргәзмәсе белән дә котләр.

Бу кадәр уңганлык-булганлык сокландыра, чөнки Люция ханым ире белән бергәләп дүрт бала да үстерә! «Балаларыбыз, әлхәмдүлилләһ, акыллылар, максатчаннар, тырышып укыйлар. Хәзер дә иҗатка вакыт табырга тырышам, сәнгать өлкәсендәге нинди дә булса яңалыкларны һәрчак барлыйм. – ди әңгәмәдәшем. – Тормышыбызда социаль челтәрләр булгач, үз эшләнмәләреңне башкаларныкы белән чагыштырып карау мөмкинлеге дә бар».

Картиналарга килгәндә, гади тормыштан алынган сюжетлы сурәтләре дә, интерьер картиналары да шактый. Рәссам табигать күренешләрен сурәтләүгә дә теләп алына... «Бу көннәрдә үзәк китапханәбез галереясында кызым Агата белән бергәләп ачкан шәхси күргәзмәбез уңыш белән бара, хезмәтләребезне ошаталар», – дип куанычын уртаклашты Люция ханым.

Агата Амосованың иҗат юлы башланып кына килә әле... Ә табигый сәләте инде сизелеп тора! Агата 13 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбендә укый. Аның һәр рәсемендә балаларга хас җете төсләр өстенлек итә. Гомумән, Амосовалар иҗатында боеклыкның әсәре дә юк, аларның иҗат эшләрендә – яктылык, матур төсләр балкышы... Бүгенге четерекле вәзгыятьтә, салкын кыш башланган чакта алар күңелгә ниндидер җылылык өсти, тормышка өмет уята.

**Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.**





AnyScanner